Республика Татарстан
Муниципальное образование город Арск
Арского муниципального района
Совет города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2024 ел** **№ 136**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында» 2024 елның 11 июнендәге 127 номерлы Арча шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында кодекс, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт хакы бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 05 сентябрендәге 731 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең

аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында» 2024 елның 11 июнендәге 127 номерлы Арча шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәнең 2 пунктын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәт хакы акчалата түләү формасында башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары | 20759 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәнең 4 пунктында (2 нче кушымта) «13323 сум» сүзләрен «13990 сум» сүзләренә алмаштырырга.

3) Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аңа хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәнең 3 пунктын (3 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарын техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы эшчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары) түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренең түләү разряды | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 21 200 |
| 2 | 1,0114 | 21 442 |
| 3 | 1,0233 | 21 694 |
| 4 | 1,0346 | 21 934 |
| 5 | 1,0473 | 22 203 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль

районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы в.б. ,
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигъмәдҗанова